## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлегенең Олы Ачасыр авылы торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында

**2023 елның 26 ноябре** **№5**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлегенең Олы Ачасыр авылы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлегенең Олы Ачасыр авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Олы Ачасыр авылында су күтәрү манарасын сатып алу һәм урнаштыру (материаллар сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);
- ирекле янгын сагы һәм махсуслаштырылган техниканы карап тоту (ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);
- Олы Ачасыр авылы территориясен төзекләндерү (территорияне пычрактан, чүп-чардан, кардан һәм боздан җыештыру, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Олы Ачасыр авыл җирлеге мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Ачасыр авыл җирлеге башлыгы ____________ И.М. Саттаров
(имза)